| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШАРШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАРШАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2020 Шаршады авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында»1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2020 елның 01 февраленнән 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 01 февраленнән җирләү буенча (якын туганнары, ире (хатыны), законлы вәкиле булган очракта) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясен расларга (1нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 01 февраленнән җирләү буенча (якын туганнары, ире (хатыны), законлы вәкиле булмаган очракта) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясен расларга (2нче кушымта).
4. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан

Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Шаршады авыл җирлеге» Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 14 мартындагы 3 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге Карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

7. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе В.Х.Бәһаветдинов

Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты
ИНН 1601006030

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2020 № 3
номерлы Карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 01 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2622,86 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 643,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2858,25 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31.01.2020 № 3
номерлы Карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 01 февраленнән якын һәм башка туганнары, ире (хатыны), законлы вәкиле булмаган очракта җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәрхүмгә гыйбадәт киеме кигезү | 471,74 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2363,85 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 579,89 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2709,38 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |